ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Ленино авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

2020 елның 23 ноябре № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлегенең Ленино авылында гражданнар җыены

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Ленино авыл җирлеге территориясендә Ленино авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, , моннан тыш, Ленино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Бөек Ватан сугышы ветеранының тол хатыны, 1 төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә 2021 елда үзара салым кертү.

2. Алынган акчаларны Ленино авылында түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү:

- Совет урамы буенча һәм аның янәшәсендәге тыкрыкларны норматив хәлгә китерү (смета буенча юл төзелеше: вак таш сатып алу, нигез әзерләү, ташу, җәю, эшләр өчен түләү);
- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш өчен түләү);
- җәйге чорда территориядәне чүп үләннәреннән чистарту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- су белән тәэмин итү системасын һәм инфраструктура объектларын проектлау, ремонтлау, карап тоту (сатып алу), килешү буенча эшләр өчен түләү, техник документацияне эшләү);
- Совет урамы, Җиңүнең 40 еллыгы урамына балалар уен мәйданчыгын сатып алу, реконструкцияләү һәм урнаштыру (җиһазлар, материаллар сатып алу һәм килешү буенча эшләү өчен түләү).»

3. Әлеге карарны Ленино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында (http:// novosheshminsk. tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә халыкка танытырга.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Ленино авыл җирлеге башлыгы М.Г.Дубровина